# МУСА ҖӘЛИЛ



## МОАБИ

## ДӘФТӘРЛӘРЕ

**Эзләнү эшенең темасы:**

# Муса Җәлилнең – «Моабит дәфтәре»



## Проектның максаты:

Муса Җәлилнең “Моабит дәфтәрләре” циклын өйрәнү .

## Бурычлар

- ✔ Муса Җәлилнең тормыш юлына, “Моабит дәфтәрләре” циклының тарихына күзәтү ясау;
- ✔ Укучыларда Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның рухи мирасын өйрәнүгә кызыксыну уяту;
- ✔ Муса Җәлил иҗатын һәм аңа бәйләп хәзерге заман әдипләренең иҗатын тирәнтен өйрәнү, пропагандалау;



# Проектның актуальлелеге:

- Халкыбызның тарихы, мәдәнияте, милли үзенчәлекләре белән кызыксынуда ;
- Балаларда патриотик хисләр, Татарстанда һәм Рәсәйдә яшәүче башка милләт халыкларына карата толерантлык тәрбияләүдә.



**Эзләнү эшенең**

***тикшерү объекты*** **–**

**Муса Җәлилнең**

**“Моабит дәфтәрләре”**

**циклы**

***тикшерү предметы*** **–**

**“Моабит дәфтәрләренең**

**үзенчәлеге”**

## *Эшнең этаплары:*

**1. Эшнең планын төзү;**

**2. Эзләнү темасы буенча мәгълүматлар җыю һәм эшкәртү;**


**3. Эзләнү эше темасы буенча класс сәгатендә, дәресләрдә, класстан тыш чараларда чыгыш ясау, конкурста катнашу.**

**Исеме**: Муса
**Фамилиясе**: Җәлилов
**Әтисенең исеме**: Мостафа
**Туган урыны**: Оренбург губернасы Мостафа авылы





**Муса Җәлилнең туган авылы**



**Муса алты яшеннән авыл мәктәбенә укырга керә, гаилә шәһәргә күчкәч, укуын “Хөсәения”мәдрәсәсендә дәвам иттерә.**

# Ул гасырлар буе балкып торыр






1945 елның маенда совет гаскәрләре фашистларның башкаласы Берлинны алды. Шундагы Моабит төрмәсен-дә сакчылар да, тоткыннар да калмаган иде инде. Сугышчыларның берсе бушап калган төрмә ишек алдында йомарланып, таушалып беткән кәгазь кисәгенә игътибар итә. Анда таныш рус хәрефләре белән нәрсәдер язылган була. Солдат кәгазьне алып, тигезли дә ниндидер немец китабыннан ертып алынган бер биткә язылган түбәндәге юлларны укый: “Мин танылган татар язучысы Муса Җәлил. Мине Моабит төрмәсенә яптылар,политик яктан гаепләделәр һәм, ихтимал, тиздән атарлар. Әгәр бу язу безнең кешеләрдән берәрсенең кулына эләксә, минем иптәшләремә – Мәскәү язучыларына миннән сәлам тапшырсын”.

Аннары шагыйрь соңгы сәламен җибәргән язучыларның фамилияләрен санап китә ( алар арасында Александр Фадеевның фамилиясе дә бар) һәм семьясының адресын күрсәтә.

Татар шагыйренең батырлыгы турында беренче хәбәр илебезгә әнә шулай килеп җитә.

«Моабит дәфтәре» (Moabit dəftəre, рус. Моаби́тская тетра́дь) — татар шагыйре Муса Җәлилнең Берлинның Моабит төрмәсендә тоткынлыкта язылган шигырьләр циклы




Моабит дәфтәрләре” - шартлы исем. Ул исемне М.Җәлил үзе куймаган. Моабит төрмәсендә дәфтәрләргә теркәлүеннән һәм байтагының төрмәдә иҗат ителүеннән чыгып, шигырьләре туган илгә кайткач шул исем белән атала башлый.
Шагыйрьнең фашист тоткынлыгындагы батырлыгы турында иң элек шушы шигырьләре сөйләде.
Дәфтәрләргә шагыйрьнең төрле хәләттә һәм әсирлекнең төрле шартларында иҗат иткән әсәрләле теркәлгән. Аларда төрле темалар, мотивлар бар, үзе кичергән фаҗигале, аяныч тормышы сурәтләнә “Кичер илем”, “Ирек”, “Кошчык” шигырьләре. Шигырьләре әсирләрдә фашистларга нәфрәт хисе тәрбияли, көрәшкә дәрт-көч уята.




Туган илгә М.Җәлилнең 2 дәфтәре кайтты. Бу дәфтәрләрнең язмышы гыйбрәтле.



Беренче дәфтәре катлаулы юллар аша Казанга 1946 елда кайтып җитә. Дәфтәрне җәлилләр утырган төрмәдән 1944 елның февралендә алып чыгалар, Франциягә аны Габбас Шәрипов алып килә, ул шигырьләр югалмый. Аларны әсир Нигъмәт Терегулов каршылык хәрәкәтендә кайнашкан француз партизанкасы Мария Дубизога сакларга тапшыра. 1946 елда Нигъмәт Терегулов Җәлил шигырьләрен Татарстан язучылар союзына тапшыра. Икенче дәфтәре дә катлаулы һәм авыр юл үтә. Анысын Бельгиялеләр саклап кала. Җәлил бу дәфтәрен бер камерада утырган бельгияле Андре Тимерманска Берлиндагы Моабит төрмәсендә судка җибәргәнче ярты ай элек тапшыра. Тимерманск аны саклый, әнисенә әйберләре белән Бельгиягә җибәрә, һәм ул Совет илчелеге аша дәфтәрне язучылар советына җибәрә.

Шулай итеп, Җәлилнең 2 дәфтәргә теркәлгән 94 шигыре туган илгә кайтып җитә.
Җәлилнең фашист тоткынлыгында иҗат иткән әсәрләре болар белән генә чикләнми, ул үзе дә бу турыда яза. Ләкин әлегә кадәр бу дәфтәрләрнең табылганы юк.
"Моабит дәфтәрләре" циклында шигырьләрне төрле тематиканы берләштерә. Җиңү, батырлык, ачыну, борчылу, өзгәләнү, ирек, туган илгә мәхәббәт, тугрылык темаларына караган әсәрләр бар.
Циклдагы әсәрләрнең төрле жанрларга караганнары бар: хат, баллада, мөрәҗәгать итеп язылган әсәрләр дә күзәтелә.
Моабит дәфтәрләрендәге шигырьләрендә төшенкелеккә бирелмәү, ныклык, батырлык темасы өстенлек итә. Аларның күбесе лирик геройның үз башыннан үткән вакыйгалар белән бәйле.




# Җәлилчеләр


Муса Җәлил
Абдулла Алиш
Абдулла Баттал
Гайнан Кормаш
Гариф Шабай
Сәлим Бохаров
Зиннәт Хәсәнов
Әхмәт Симай
Әхәт Атнашев
Фоат Булатов
Фәрит Сәйфелмөлеков

# Тоткынлыкта









**1956 елның 2 февралендә немец-фашист илбасарларга каршы сугышта искиткеч ныклык һәм батырлык күрсәткән өчен, өлкән политрук Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое дигән исем бирелә.**



**Ә 1957 елда “Моабит дәфтәре” шигырьләре циклы өчен ул, шагыйрьләр арасында беренче булып, Ленин премиясенә лаек була.**











Башкалабыз Казан шәһәренең үзәгендә торучы –горур һәйкәле,татар халкының гына түгел, чит ил кунакларының да яраткан урыны булган “Муса Җәлил исемендәге Татар академиясенең опера-балет театры”, парк-музейлар, аның мәңге үлмәс исемен, бөеклегән исбатлыйлар.

Проект эшендә катнашучылар:

Актаныш 1нче гомуми урта белем бирү мәктәбенен 3 а класс укучылары, класс җитәкчесе, ата –аналары, китапханәчеләр.



**Закирова Камила**



**Фахразиев Раяз**



**Ильясова Энҗе**


2019-2-14 09:58
Муса
LOVE
PEACE
SKATE














МУСА Җ ӘЛИЛ
ТИЛГӘН






## ЙОМГАК



Әлеге эзләнү эшендә без  Муса Җәлилнең биографиясе, “Моабит дәфтәрләре” циклының тарихы белән таныштык. Нәтиҗә ясап әйткәндә, Муса Җәлил – күп милләтле совет әдәбиятының мактанычы һәм горурлыгы. Аның бай иҗаты, тоткынлыкта күрсәткән тиңдәшсез батырлыгы бер безне генә түгел, киләчәк буыннарны да таң калдырыр. Мусага хас Ватанны сөю хисе, аның олы җаны һәм кешелеклеге миллионнар өчен үрнәк булып кала. Ватанына тугрылыклы калган кеше генә әнә шундый үлмәс әсәрләр иҗат итә аладыр.





Үзем үлсәм, исемем,
җырым үлмәс,
Ул яңгырар илнең кырында

Муса Җәлил

# Кулланылган әдәбият:


1. Кашшаф Г. Муса Җәлил. – Казан: Комбинат печати им. Камиля Якуба, - 1961. – 458 б.
2. Кашшаф Г. Муса Җәлил. Фотоальбом, - Казан: Комбинат печати им. Камиля Якуба, - 1966. – 191 б.
3. Мостафин Р.Ә. Җәлилчеләр: Очерклар, җәлилчеләр иҗаты, - Казан: Татар. кит. нәшр. ,1988. – 263 б.
4. Мостафин Р.Ә. 1т.: Муса Җәлил. Шигырьләр (1921-1941), – Казан: Татар. кит. нәшр. , 2006. – 431 б.
5. Мостафин Р.Ә. Муса Җәлил турында истәлекләр, - Казан: Татар. кит. нәшр. , 2006. – 319 б.
6. Мостафин Р.Ә. Өзелгән җыр эзеннән. Документаль повестьлар, - Казан: Татар. кит. нәшр. , 1982. – 464 б.
7. Мостафин Р.Ә. Үлмәс җыр, - Казан: Татар. кит. нәшр. ,1971. - 248 б.